27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.27 һәм 32.4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1165426-6 номерлы федераль закон проекты турында (лотереялар үткәрүне (таратуны) Россия Федерациясе Хөкүмәте рөхсәтеннән башка башкарган өчен лотерея терминалларын һәм җиһазларын конфискацияләүне кертү хакында).

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1145320-6 номерлы федераль закон проекты турында (рөхсәтсез нефрит чыгарган һәм законсыз чыгарылган нефритны саткан өчен административ җаваплылык билгеләү хакында).

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1120249-6 номерлы федераль закон проекты турында (эшкуарлык эшчәнлеген махсус рөхсәт алмыйча алып барган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 14.56 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1120970-6 номерлы федераль закон проекты турында (микрофинанс оешмаларының эшчәнлеген камилләштерү өлешендә).

31. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1095451-6 номерлы федераль закон проекты турында (эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә инвалидларның хокукларын бозган өчен юридик затларның җаваплылыгын билгеләү өлешендә).

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1082383-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяның редакциясен төгәлләштерү хакында).

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1094316-6 номерлы федераль закон проекты турында (архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу яисә алардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында).

34. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 1177587-6 номерлы федераль закон проекты хакында (саклау объектларында һәм территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлеше буенча дәүләт янгынга каршы күзәтчелеге эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә).

35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1118805-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларын кулланып кылган, шулай ук фотога, кинога һәм видеога төшерүнең башка чаралары ярдәмендә теркәлгән Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган аерым хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту мөмкинлеге хакында).

36. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына яшелләндерелгән территорияләрдә транспорт чараларында йөргән һәм аларны куеп торган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1131294-6 номерлы федераль закон проекты турында.

37. «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» Федераль законның 11 һәм 20 статьяларына һәм «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1186354-6 номерлы федераль закон проекты турында (мобилизацион әзерлек һәм мобилизация өлкәсендәге бурычларны үтәүгә шәхсән җаваплы булган федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның аерым вазыйфаи затларының категорияләрен, шулай ук мобилизация буенча чакыру комиссияләре төзү тәртибен һәм мобилизация буенча чакыру комиссияләре (чакыру комиссияләре) составын төгәлләштерү хакында).

38. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

39. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында».

40. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1430-V ДС



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 953. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп ун елга түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре суд районы буенча:

8 нче суд участогына — Гомәрова Фирая Габделгазиз кызын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1431-V ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 954. Павлова Ольга Ивановнаның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты булып сайлануга бәйле рәвештә, «Бердәм Россия» сәяси партиясеннән бердәм республика сайлау округы буенча сайланган Павлова Ольга Ивановнаның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләре, аның депутат вәкаләтләрен туктату турындагы язма гаризасы нигезендә, 2016 елның 30 сентябреннән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

2. Павлова Ольга Ивановнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составыннан чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетын сайлау турында» 2014 елның 1 октябрендәге 17-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының икенче абзацына, «13» санын «12» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1432-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 955. «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 282-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 282-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2016 елның 12 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2016 елның 21 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1433-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 956. «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 283-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 283-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2016 елның 12 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2016 елның 21 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1434-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 957. «Татарстан Республикасында азык-төлек продукциясенең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы законы хакында (253-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында азык-төлек продукциясенең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы законын (253-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1435-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 958. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 258-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 258-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1436-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 959. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (258-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (258-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1437-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 960. «Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Алан авылының гамәлдә булуын юкка чыгару һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 281-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Түбән Кама муниципаль район Советы тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Алан авылының гамәлдә булуын юкка чыгару һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен

билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 281-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1438-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 961. «Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Алан авылының гамәлдә булуын юкка чыгару һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (281-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Алан авылының гамәлдә булуын юкка чыгару һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (281-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1439-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 962. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 279-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев, Р.Р. Гайзатуллин, И.Г. Ганиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 279-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1440-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 963. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (279-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын (279-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1441-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 964. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 278-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев, Р.Р. Гайзатуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 278-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1442-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 965. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (278-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (278-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1443-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 966. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 280-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев, Р.Р. Гайзатуллин, Р.Ә. Сөләйманов, Р.Ш. Җаббарова тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 280-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1444-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 967. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (280-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (280-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1445-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 968. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 274-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 274-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1446-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 969. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (274-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (274-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1447-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 970. «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 275-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 275-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1448-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 971. «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (275-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (275-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1449-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 972. «Вөҗдан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 276-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Вөҗдан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 276-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1450-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 973. «Вөҗдан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (276-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Вөҗдан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (276-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1451-V ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 974. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына (2010 елның 9 июнендәге 973-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 3 (II өлеш), № 10 (II өлеш), № 12 (V өлеш); 2006, № 1, № 10 (I өлеш); 2007, № 10, № 12 (IV өлеш); 2008, № 11 (IV өлеш); 2010, № 6 (III өлеш); 2011, № 3, № 12; 2013, № 5, № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); 2015, № 1 – 2, № 6 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе» сүзләрен өстәргә;

2) 48 статьяда:

а) 1 өлештә «җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары рәисләре» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары рәисләре,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе,» сүзләрен өстәргә;

3) 62 статьяның 3 өлешендә «җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары рәисләре» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе» сүзләрен өстәргә;

4) 73 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Һәр тавыш бирүдә депутат бер тавышка ия була.»;

5) 87 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы

нигезендә җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиешле, күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы нигезендә җайга салу йогынтысын бәяләүне узмаган закон проекты, җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыруны оештыру өчен, Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына җибәрелә.»;

6) 92 статьяның 3 өлешендә:

а) 10 пунктта «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган закон проектлары буенча Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы бәяләмәсен (булган очракта).»;

7) 94 статьяның 3 өлешендә «Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

8) 95 статьяның 2 өлешендә «Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

9) 144 статьяда:

а) «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны» сүзләрен «1.



Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны килештерү өчен Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә җибәрелә.»;

10) 145 статьяның 1 өлешендә «кандидатура» сүзеннән соң «Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештерелгәннән соң» сүзләрен өстәргә;

11) түбәндәге эчтәлекле $189^2$ статья өстәргә:

1. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы календарь ел тәмамланганнан соң Дәүләт Советына Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында еллык доклад җибәрә.

2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Рәисе Дәүләт Советы утырышында еллык доклад белән чыгыш ясый.

3. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Рәисенең еллык докладын карау нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының үсешен тоткарлый торган ачыкланган сәбәпләрне бетерү чараларын күрә, бу хакта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына хәбәр ителә.».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1452-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**975. «Татарстан Республикасының Граждан хәле актларын теркәү органнары хезмәткәре көнен билгеләү турында»**

«Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

18 декабрьне һөнәри бәйрәм — Татарстан Республикасының Граждан хәле актларын теркәү органнары хезмәткәре көне итеп билгеләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1453-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**976. «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» Федераль законның 51 һәм 53 статьяларына һәм «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның 28 июнендәге 1335-V ДС номерлы карарына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» Федераль законның 51 һәм 53 статьяларына һәм «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның 28 июнендәге 1335-V ДС номерлы карарына, 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Күрсәтелгән федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкилләр итеп Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Борһанов Рафис Тимерхан улын һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.».

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1454-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**977. «Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 447 һәм 448 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 447 һәм 448 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1455-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 978. «Бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 1160742-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 1160742-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1456-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 979. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 2[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» 1165647-6 номерлы федераль закон проекты турында (федераль әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген киңәйтү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 2[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» 1165647-6 номерлы федераль закон проектын (федераль әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген киңәйтү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1457-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 980. «Дәүләт яисә муниципаль милектәге һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керә торган Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 1177357-6 номерлы федераль закон проекты турында (җир кишәрлекләре бирү тәртибен һәм шартларын төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Дәүләт яисә муниципаль милектәге һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керә торган Россия

Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 1177357-6 номерлы федераль закон проектын (җир кишәрлекләре бирү тәртибен һәм шартларын төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1458-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 981. «Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1459-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 982. «Ябык административ-территориаль берәмлек турында» Россия Федерациясе Законына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1148859-6 номерлы федераль закон проекты турында (ябык административ-территориаль берәмлекне үзгәртеп кору, бетерү һәм аның чикләрен үзгәртү тәртибен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Ябык административ-территориаль берәмлек турында» Россия Федерациясе Законына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1148859-6 номерлы федераль закон проектын (ябык административ-территориаль берәмлекне үзгәртеп кору, бетерү һәм аның чикләрен үзгәртү тәртибен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1460-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 983. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1112847-6 номерлы федераль закон проекты хакында (банкротлыкның аерым процедураларын гамәлгә ашыру тәртибен үзгәртү һәм дәүләт сатып алуларында катнашучылар өчен өстәмә чикләүләр билгеләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1112847-6 номерлы федераль закон проектын (банкротлыкның аерым процедураларын гамәлгә ашыру

төртибен үзгәртү һәм дәүләт сатып алуларында катнашучылар өчен өстәмә чикләүләр билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1461-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 984. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 2.9 һәм 7.21 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1101980-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ җаваплылыкны либеральләштерү, шул исәптән озак вакыт дәвамында административ хокук бозу башкарылганда — торак йортны һәм (яисә) торак урыннарны рөхсәтсез үзгәртеп төзегәндә һәм (яисә) планировкасын үзгәрткәндә, шулай ук күпфатирлы йортларда торак урыннарның планировкасын үзгәрткәндә, мәсьәләләре өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 2.9 һәм 7.21 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1101980-6 номерлы федераль закон проектын (административ җаваплылыкны либеральләштерү, шул исәптән озак вакыт дәвамында административ хокук бозу башкарылганда — торак йортны һәм (яисә) торак урыннарны рөхсәтсез үзгәртеп төзегәндә һәм (яисә) планировкасын үзгәрткәндә, шулай ук күпфатирлы йортларда торак урыннарның планировкасын үзгәрткәндә, мәсьәләләре өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1462-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 985. «Дәүләт оборона заказы турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1112745-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт оборона заказы турындагы законнарның үтәлешен тикшерүне башкарганда законнарның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Дәүләт оборона заказы турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1112745-6 номерлы федераль закон проектын (дәүләт оборона заказы турындагы законнарның үтәлешен тикшерүне башкарганда законнарның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1463-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 986. «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1167404-6 номерлы федераль закон проекты хакында (башкару документларын күрсәтү сроклары турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1167404-6 номерлы федераль закон проектын (башкару документларын күрсәтү сроклары турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1464-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 987. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.27 һәм 32.4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1165426-6 номерлы федераль закон проекты турында (лотереялар үткәрүне (таратуны) Россия Федерациясе Хөкүмәте рөхсәтеннән башка башкарган өчен лотерея терминалларын һәм җиһазларын конфискацияләүне кертү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.27 һәм 32.4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1165426-6 номерлы федераль закон проектын (лотереялар үткәрүне (таратуны) Россия Федерациясе Хөкүмәте рөхсәтеннән башка башкарган өчен лотерея терминалларын һәм җиһазларын конфискацияләүне кертү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1465-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 988. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1145320-6 номерлы федераль закон проекты турында (рөхсәтсез нефрит чыгарган һәм законсыз чыгарылган нефритны саткан өчен административ җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1145320-6 номерлы федераль закон проектын (рөхсәтсез нефрит чыгарган һәм законсыз чыгарылган нефритны саткан өчен административ җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1466-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 989. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1120249-6 номерлы федераль закон проекты турында (эшкуарлык эшчәнлеген махсус рөхсәт алмыйча алып барган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1120249-6 номерлы федераль закон проектын (эшкуарлык эшчәнлеген махсус рөхсәт алмыйча алып барган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1467-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**990. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 14.56 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1120970-6 номерлы федераль закон проекты турында (микрофинанс оешмаларының эшчәнлеген камилләштерү өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 14.56 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1120970-6 номерлы федераль закон проектын (микрофинанс оешмаларының эшчәнлеген камилләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1468-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**991. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1095451-6 номерлы федераль закон проекты турында (эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә инвалидларның хокукларын бозган өчен юридик затларның җаваплылыгын билгеләү өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1095451-6 номерлы федераль закон проектын (эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә инвалидларның хокукларын бозган өчен юридик затларның җаваплылыгын билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1469-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**992. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1082383-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяның редакциясен төгәлләштерү хакында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1082383-6 номерлы федераль закон проектын (статьяның редакциясен төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1470-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**993. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1094316-6 номерлы федераль закон проекты турында (архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу яисә алардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1094316-6 номерлы федераль закон проектын (архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу яисә алардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1471-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**994. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 1177587-6 номерлы федераль закон проекты хакында (саклау объектларында һәм территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлеше буенча дәүләт янгынга каршы күзәтчелеге эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 1177587-6 номерлы федераль закон проектын (саклау объектларында һәм территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлеше буенча дәүләт янгынга каршы күзәтчелеге эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1472-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**995. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1118805-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларын кулланып кылган, шулай ук фотога, киногa һәм видеога төшерүнең башка чаралары ярдәмендә теркәлгән Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган аерым хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту мөмкинлеге хакында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1118805-6 номерлы федераль закон проектын (транспорт чараларын кулланып кылган, шулай ук фотога, киногa һәм видеога төшерүнең башка чаралары ярдәмендә теркәлгән Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган аерым хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту мөмкинлеге хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1473-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**996. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына яшелләндерелгән территорияләрдә транспорт чараларында йөргән һәм аларны куеп торган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1131294-6 номерлы федераль закон проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына яшелләндерелгән территорияләрдә транспорт чараларында йөргән һәм аларны куеп торган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1131294-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1474-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**997. «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» Федераль законның 11 һәм 20 статьяларына һәм «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1186354-6 номерлы федераль закон проекты турында (мобилизацион әзерлек һәм мобилизация өлкәсендәге бурычларны үтәүгә шәхсән җаваплы булган федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның аерым вазыйфаи затларының категорияләрен, шулай ук мобилизация буенча чакыру комиссияләре төзү тәртибен һәм мобилизация буенча чакыру комиссияләре (чакыру комиссияләре) составын төгәлләштерү хакында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» Федераль законның 11 һәм 20 статьяларына һәм «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1186354-6 номерлы федераль закон проектын (мобилизацион әзерлек һәм мобилизация өлкәсендәге бурычларны үтәүгә шәхсән җаваплы булган федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның аерым вазыйфаи затларының категорияләрен, шулай ук мобилизация буенча чакыру комиссияләре төзү тәртибен һәм мобилизация буенча чакыру комиссияләре (чакыру комиссияләре) составын төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1475-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**998. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Чуваш Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1476-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**999. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Барышев гарызнамәсе турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Премьер-министры И.Ш. Халиковка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Барышевның каты коммуналь калдыкларның муниципальара полигонының Алабуга муниципаль районында урнашуы турындагы гарызнамәсен җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 3 ноябре
№ 1477-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1000. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме өченче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме өченче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

2. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 285-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

3. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 293-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

4. «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 282-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

5. «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 283-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

6. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 260-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

